МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.07.2018 г.Казань № 593

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2018 елның 14 августында теркәлде, № 4836

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) буенча конкурс уздыру турында нигезләмә раслау хакында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү һәм дәүләт органнары кадрлар резервына кертү буенча конкурслар уздыруның бердәм методикасын раслау турында» 2018 елның 31 мартындагы 397 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү һәм дәүләт органнары кадрлар резервына кертү буенча конкурслар уздыруның бердәм методикасы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмә раслау турында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре» 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы Указлары нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль

яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) буенча конкурс уздыру турында кушымтада бирелгән нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының түбәндәге боерыкларын көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс уздыру методикасын раслау турында» 2011 елның 10 маендагы 244 номерлы;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2011 елның 10 маендагы 244 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру методикасына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 26 июлендәге 455 номерлы;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2011 елның 10 маендагы 244 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру методикасына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 12 маендагы 254 номерлы;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2011 елның 10 маендагы 244 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру методикасына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 09 октябрендәге 712 номерлы.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 18 июленедә 593 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) буенча конкурс уздыру турында нигезләмә

1.1 Әлеге Нигезләмәдә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясенең составы, эшләү чоры һәм тәртибе билгеләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс (алга таба тиешенчә – вакантлы вазыйфа биләүгә конкурс, кадрлар резервына кертүгә конкурс, конкурслар) Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт хезмәтенә карата тигез дәрәҗәдә үтеп керә алуы буенча конституциячел хокукларын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукын тәэмин итә.

1.2 Министрлыкта конкурс «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы (алга таба – Федераль закон), Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү һәм дәүләт органнары кадрлар резервына кертү буенча конкурслар уздыруның бердәм методикасын раслау турында» 2018 елның 31 мартындагы 397 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү һәм дәүләт органнары кадрлар резервына кертү буенча конкурслар уздыруның бердәм методикасы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмә раслау турында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре» 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы указлары нигезендә үткәрелә.

1.3 Конкурслар конкурсларда катнашуга кертелгән Россия Федерациясе гражданнарының (дәүләт граждан хезмәткәрләренең) (алга таба – кандидатлар) профессиональ дәрәҗәсен, шулай ук аларның тиешле граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә (алга таба тиешенчә – кандидатларны бәяләү, квалификация таләпләре) туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.4 Министрлыкта вакантлы вазыйфа биләүгә конкурс Федераль закон нигезендә дәүләт граждан хезмәтенең (алга таба – граждан хезмәте) конкурс нигезендә биләнә торган вакантлы вазыйфасы булганда Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – министр) карары нигезендә игълан ителә.

1.5 Министрлыкның кадрлар резервына кертүгә карата конкурс дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге тарафыннан, Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү буенча белгечләргә мөмкин булган ихтыяҗны һәм Министрлыктагы кадрлар резервын ел саен бәяләү нәтиҗәләре буенча оештырыла.

Министрлыкның кадрлар резервына кертүгә конкурс Министрлыкның конкурс комиссиясе тарафыннан әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә үткәрелә.

1.6 Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

билгеле бер чорга биләнә торган «җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфасы вәкаләтләрен биләү өчен билгеләнгәндә;

вакытлы хезмәт контрактын төзегәндә;

Федераль законның 28 статьясының 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм 60.1 статьясының 9 өлешендә каралган очракларда граждан хезмәткәрен дәүләт граждан хезмәтенең бүтән вазыйфасына билгеләгәндә;

Татарстан Республикасы граждан хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәрен (гражданинны) граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

1.7 Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелмәскә мөмкин:

алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, Министрлык боерыгы нигезендә расланучы вазыйфалар исемлегендә аерым граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә;

министр карары нигезендә, граждан хезмәтенең кече вазыйфалар төркеменә карый торган граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә.

1.8 Конкурслар түбәндәге максатларда үткәрелә:

сәләтләре һәм профессиональ әзерлеге нигезендә граждан хезмәтенә тигез дәрәҗәдә үтеп керүдә Россия Федерациясе гражданнарының конституциячел хокукларын, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукларын тәэмин итү;

граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча аеруча туры килә торган кандидатларны федераль законнарда, Татарстан Республикасы

законнарында, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатларның гомуми саны арасыннан сайлап алу;

граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Министрлыкның кадрлар резервын формалаштыру.

1.9 Конкурсларны үткәргәндә хәл ителә торган мәсьәләләр:

барлык кандидатлар өчен дә алар тарафыннан конкурс биремнәре һәм процедуралары үтәлгәндә тигез шартларны тәэмин итү;

объектив һөнәри әһәмиятле критерияләр нигезендә кандидатларны бәяләү;

конкурста катнашучылар арасыннан, конкурс процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезле күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән, квалификация таләпләренә туры килә торган кандидатларны ачыклау.

1.10. Кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерергә хокуклы.

1.11. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дәгъва белдергән, ләкин конкурста катнашуга кертелмәгән кандидатларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары язма гаризалары буенча конкурс тәмамланган көннән соң өч ел дәвамында аларга кайтарып бирелергә мөмкин. Әлеге чор тәмамланганчыга кадәр документлар Министрлык архивында саклана, аннан соң юкка чыгарылырга тиеш. Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә тапшырылган документлар өч ел саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш.

1.12. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрелгән урынга бару һәм кайту, торак урынга түләү, яшәү, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һәм башкасы) кандидатлар тарафыннан үз акчалары хисабыннан түләнә.

## II. КОНКУРС КОМИССИЯСЕ ТӨЗҮ ҺӘМ АНЫҢ ЭШЛӘҮ ТӘРТИБЕ

2.1. Конкурсларны үткәрү өчен Министрлык боерыгы белән даими нигездә гамәл кылучы конкурс комиссиясе төзелә. Комиссия составына кертелгән вазыйфаи затларның шәхси составы үзгәртелгәндә, министр боерыгы белән тиешле үзгәрешләр кертелә.

2.2. Конкурс комиссиясе Рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.3. Комиссия рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда аның хокукларын һәм бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясенең сәркатибе конкурс комиссиясенең эшен тәэмин итә (гаризаларны кабул итү, эшләрне формалаштыру, конкурс комиссиясе утырышлары карарларын рәсмиләштерү һ.б.).

2.4. Конкурс комиссиясе составына министрның беренче урынбасары һәм Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегеннән, Министрлыкның юридик

бүлегеннән һәм Министрлыкның граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) конкурс уздырыла торган структур бүлекчәсеннән (алга таба – Министрлыкның структур бүлекчәсе вәкиле) министр тарафыннан вәкаләт бирелгән граждан хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук министр гарызнамәсе буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан бәйсез экспертлар – граждан хезмәтенә бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр сыйфатында экспертларның шәхси мәгълүматларын күрсәтмичә чакыртыла торган фәнни, мәгариф һәм башка оешмаларның вәкилләре керә.

Структур бүлекчәләрнең вәкилләре конкурста катнашучылар арасыннан бары тик Министрлыкның вакантлы граждан хезмәте вазыйфаларына карата (граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә) карата конкурс игълан ителгән структур бүлекчәсендә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен кадрлар резервына кертүгә) дәгъва белдерүчеләрне караганда гына конкурс эшендә катнашалар.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет әгъзаларының һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясендәге барлык әгъзаларның кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

2.5. Граждан хезмәтенең вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздырылганда конкурс комиссиясе составы Россия Федерациясенең дәүләт сере турында законнары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

2.6. Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеге калмаслык итеп төзелә.

Конкурс комиссиясе эшенең объективлык һәм бәйсезлек дәрәҗәсен арттыру максатларында Министр карары нигезендә аның составы ел саен яңартылып тора.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми исәбендәге кимендә өчтән ике өлеше катнашса, ул тулы хокуклы булып санала.

Конкурс комиссиясе утырышын бары тик комиссиянең граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалары составында гына үткәрү рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясенең карары кандидат юклыгында кабул ителә.

Конкурс уздыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү нигезендә утырышта катнашкан әгъзалары тавышларының гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, конкурс комиссиясенә рәислек итүче затның тавышы хәл иткеч була.

2.9. Конкурсны турыдан-туры оештыруны һәм уздыруны, конкурс комиссиясе эшен тәэмин итүне Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге гамәлгә ашыра.

## III. КОНКУРСТА КАТНАШУЧЫЛАР

3.1. Квалификация таләпләренә җавап бирә торган һәм әлеге Нигезләмәнең 3.5 пунктында күрсәтелгән документларны әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктында каралган срокта тапшырган гражданнар конкурсларда катнашуга кертелә.

3.2. Квалификация таләпләренә җавап бирмәве, шулай ук Федераль законда билгеләнгән чикләмәләре булуга бәйле рәвештә гражданин (граждан хезмәткәре) конкурсларда катнашуга кертелми.

3.3. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен кандидатларга карата таләпләр дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнде.

3.4. Россия Федерациясенең конкурсларда катнашырга теләк белдергән гражданины Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасына туры китерелгән формада шәхси гариза;

Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган формада тутырылган һәм имзаланган анкета, фото белән;

паспорт яки аны алмаштыра торган документ (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә) күчермәсе;

кирәкле һөнәри белемне, квалификацияне һәм эш стажын раслый торган документлар:

хезмәт кенәгәсенең (хезмәт итүгә (эшләүгә) бәйле эшчәнлек беренче мәртәбә гамәлгә ашырыла торган очраклардан кала) нотариаль яктан яки хезмәт итү (эшләү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе яки гражданинның эшләвен (хезмәт эшчәнлеген) раслый торган бүтән документлар;

белем алу турында һәм квалификация турында документларның күчермәләре, шулай ук, ихтыяры буенча, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүне яки бирелүне раслый торган документларның, фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирелү турында документларның нотариаль яктан яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәләре;

гражданинда граждан хезмәтенә керүгә яки аны үтүгә комачаулый торган чирләрнең юклыгы турында документ (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2009 елның 14 декабрендәге № 984н боерыгы белән расланган 001-ГС/у исәп рәвеше);

Федераль законда, башка федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган бүтән документлар.

3.5. Конкурслара катнашу теләген белдергән, Министрлыкта граждан хезмәте вазыйфасын биләүче граждан хезмәткәре гаризаны министр исеменә тапшыра.

Бүтән дәүләт органында вазыйфа биләүче, конкурсларда катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәре Министрлыкка министр исеменә шәхси гариза һәм үзе тутырган, имзалаган һәм үзе граждан хезмәтен били торган дәүләт органының

резервына кертү буенча конкурслар уздыруның бердәм методикасы (алга таба – Конкурслар уздыруның бердәм методикасы) белән билгеләнгән бәяләү методлары һәм бәяләү методларына тасвирлама нигезендә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфалар категорияләренә һәм төркемнәренә (кадрлар резервы формалаштырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеменә) карап гамәлгә ашырыла.

Конкурс комиссиясе әгъзалары бәяләү методларын куллану һәм конкурс биремнәрен формалаштыру турында тәкъдимнәр кертергә хокуклы.

4.2. Конкурслар ике этапта үткәрелә.

4.3. Беренче этапта Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге түбәндәгеләрне оештыра:

конкурсларны уздыру турында мәгълүматны әзерли һәм Министрлыкның рәсми сайтында һәм Федераль мәгълүмат системасында урнаштыра, ул үз эченә түбәндәгеләрне ала: граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасының (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасының) аталышы, әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъва белдерүче затка белдерелә торган квалификация таләпләре, граждан хезмәткәренең вазыйфаи регламентының вазыйфаи бурычларын, хокукларын һәм вазыйфаи бурычларны үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен җаваплылыгын үз эченә ала торган нигезләмәләре, граждан хезмәткәренең профессиональ хезмәт эшчәнлегендә файдалылык һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре, граждан хезмәтен узу шартлары, дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү (кадрлар резервына керү) өчен кандидатлар тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документлар һәм материаллар нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, күрсәтелгән документлар кабул ителә торган срок, конкурсны уздыруның күздә тотылган датасы, аны уздыру урыны һәм тәртибе, бәяләү методлары һәм бәяләү методларына тасвирлама, профессиональ дәрәҗәне мөстәкыйль бәяләү өчен конкурстан читтә дәгъва белдерүчеләрнең Россия Федерациясе дәүләт телен (рус телен) белү дәрәҗәсен, Россия Федерациясе Конституциясе, дәүләт хезмәте турында һәм коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнары нигезләрен белү, мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендәге белемнәре һәм күнекмәләре дәрәҗәсен бәяләү өчен биремнәрне үз эченә алган, Федераль дәүләт мәгълүмат системасы рәсми сайтында урнаштырылган беренчел квалификация тесты (алга таба – беренчел тест) турында мәгълүмат һәм башка төрле мәгълүмат материаллары;

кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны тикшерә:

гражданның (граждан хезмәткәренең) квалификация таләпләренә туры килүен (һөнәри белем дәрәҗәсен, граждан хезмәте (бүтән төрле граждан хезмәтенең) стажын яки белгечлеге буенча эшләү стажын (тәҗрибәсен), әзерлек юнәлешен, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәрен һәм күнекмәләрен) тикшерә.

4.4. Тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары нигезендә гражданинның граждан хезмәтенә керүенә каршы килә торган шартлар ачыкланганда, аңа министр тарафыннан язмача рәвештә конкурста катнаштырудан баш тартуның сәбәпләре хакында хәбәр ителә. Әгәр

кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган формадагы анкетаны фотосын теркәп тапшыра.

3.6. Гражданинның (граждан хезмәткәренең) ризалыгы белән аңа дәүләт серен яки закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга рөхсәт бирү процедурасы рәсмиләштерелә, әгәр гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан биләү өчен дәгъва белдерелгән граждан хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү мондый белешмәләрдән файдалануга бәйле булса.

Гражданинның министр исеменә тапшырылган белешмәләренең дөрес булу-булмавы тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә тапшырылган белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылган рәвештә тикшерелә.

3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.4 һәм 3.5 пунктларында күрсәтелгән документлар аларны кабул итү турында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы рәсми сайтында (алга таба – Федераль мәгълүмат системасы) игълан урнаштырылган көннән башлап 21 календарь көне эчендә дәүләт органына гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан шәхсән, почта аша җибәреп яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә күрсәтелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон рәвештә җибәрелә.

Хөрмәткә лаек сәбәпсез документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданиннан (граждан хезмәткәреннән) аларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булып тора.

Хөрмәткә лаек сәбәп аркасында документларны үз вакытында тапшырмаганда, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда министр аларны кабул итү вакытын күчерергә хокуклы.

## IV. КОНКУРСНЫ УЗДЫРУ МЕТОДИКАСЫ

4.1. Конкурсларны уздыруга әзерлек кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларын (алга таба – бәяләү методлары) сайлауны һәм аларга туры килә торган конкурс биремнәрен формалаштыруны, граждан хезмәтенең аларны биләү буенча конкурслар игълан итү планлаштырыла торган вакантлы вазыйфаларына (алга таба – граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфалары) карата граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентлары нигезләмәләрен актуальләштерүне күздә тота.

Кандидатларның квалификация таләпләренә туры килүен бәяләү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү һәм дәүләт органнары кадрлар резервына кертү буенча конкурслар уздыруның бердәм методикасын раслау турында» 2018 елның 31 мартындагы 397 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү һәм дәүләт органнары кадрлар

гражданин конкурсларда катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган булса, конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләре хакында хәбәрләмә аңа, Федераль мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

4.5. Конкурсларда катнашуга кертелмәгән, вакантлы вазыйфаны биләү өчен дәгъва белдергән зат бу карарга Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерергә хокуклы.

4.6. Министрлыкта граждан хезмәтенең бер вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) карата куелган квалификация таләпләренә җавап бирә торган кимендә ике кандидат булуы конкурсларның беренче этабын төгәлләү шарты булып тора, бу хәл кандидатларны алга таба сайлау мөмкинлеген тәэмин итә.

Кандидатлар булмаганда яисә вазыйфага карата квалификация таләпләренә җавап бирә торган бары тик бер генә кандидат булган очракта, конкурс узмаган дип таныла. Бу очракта бердәнбер кандидатка таләп ителүче кандидатлар саны булмауга бәйле рәвештә конкурсның узмаган дип танылуы хакында язмача хәбәр ителә.

4.7. Конкурсларның беренче этабы тәмамлангач министр конкурсның икенче этабын уздыру датасы (катнашу өчен документлар кабул итү тәмамланганнан соң 30 календарь көне узганчы), вакыты һәм урыны турында карар кабул итә. Дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга рөхсәт рәсмиләштерелгән очракта, конкурсның икенче этабын уздыру чорын министр билгели.

Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге, конкурсның икенче этабы башланырга 15 календарь көне калганчы, Министрлыкның рәсми сайтында һәм Федераль мәгълүмат системасында аны уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында мәгълүмат, конкурста катнашуга кертелгән кандидатлар исемлеген урнаштыра һәм кандидатларга язмача рәвештә тиешле хәбәрләмәләрне җибәрә, бу вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга, – аталган системадан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында.

4.8. Конкурсларның икенче этабында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатлары бәяләнә;

Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурста җиңүчене билгеләү турында конкурс комиссиясе карары кабул ителә.

4.9. Конкурсларны уздырганда конкурс комиссиясе кандидатларны алар тарафыннан тапшырылган белеме, граждан яки башка төрле дәүләт хезмәтен узуы, башка төрле хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруы турындагы документлары нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын 100 баллы система буенча бәяләү методларыннан файдаланып, конкурс процедуралары нәтиҗәләре нигезендә бәяли.

4.10. Кандидатларның профессиональ дәрәҗәсен, аларның квалификация таләпләренә туры килүен бәяләү өчен конкурс процедуралары барышында бәяләү методлары кулланыла, алар реферат яки башка төрле язма эшләр язуны, тест уздыруны, шәхси әңгәмә уздыруны үз эченә алырга мөмкин.

Тест уздыру һәм шәхси әңгәмә уздыру кандидатларны бәяләүнең зарури методлары булып тора.

4.11. Кандидатларның конкурс биремнәрен үтәгәндә контроль тәэмин итү максатында конкурс процедуралары барышында конкурс комиссиясе вәкилләре катнаша. Конкурс комиссиясе әгъзалары аның утырышы башланырга кимендә 3 эш көне калганчы кандидат тарафыннан үтәлгән конкурс биремнәре материаллары белән танышырга тиеш. Күрсәтелгән материалларның исемлеге конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан билгеләнә.

Кандидат конкурс биремнәрен үтәгәндә һәм конкурс комиссиясе утырышын үткәргәндә эшкә алучының вәкиле карары нигезендә видеога һәм (яки) аудиога яздыру эше яки тиешле конкурс процедураларын уздыруның стенограммасы алып барыла.

4.12. Реферат яки башка төрле язма эшне язу өчен граждан хезмәтенең конкурс уздырыла торган вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү буенча конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме) буенча вазыйфаи бурычлардан, шулай ук аталган вазыйфаларны биләү өчен квалификация таләпләреннән чыгып төзелгән сораулар яки биремнәр кулланыла.

Рефератның яки башка төрле язма эшнең темасы, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча конкурс уздырылган очракта, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен конкурс уздырыла торган Министрлыкның структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан, ә кадрлар резервына кертүгә конкурс уздырылган очракта, кадрлар резервына кертү өчен конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча профессиональ хезмәт эшчәнлеге өлкәсе гамәлгә ашырыла торган Министрлыкның структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан билгеләнә һәм конкурс комиссиясе рәисе белән килештерелә.

Конкурс комиссиясе утырышына кадәр кимендә 10 календарь көне кала кандидатларга рефератның яки башка төрле язма эшнең темасы җибәрелә.

Реферат яки башка төрле язма эш түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

рефератның күләме – 3 биттән 4 биткә кадәр;

шрифты – Times New Roman, зурлыгы 14, берле интервал аша.

Реферат яки башка төрле язма эш кандидатлар тарафыннан конкурс комиссиясе сәркатибенә конкурс комиссиясе утырышын уздырырга кимендә 10 календарь көне калганчы тапшырыла.

Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздырылган очракта рефератка яки башка төрле язма эшкә Министрлыкның граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча конкурс уздырыла торган структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан язмача бәяләмә, ә кадрлар резервына керү буенча конкурс уздырылган очракта, Министрлыкта кадрлар резервына кертү буенча конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча профессиональ

хезмәт эшчәнлеге өлкәсе гамәлгә ашырыла торган структур бүлекчәсе җитәкчесенең бәяләмәсе бирелә. Бу вакытта объектив бәяләү уздыру максатларында әзерләнгән рефератның яки башка төрле язма эшнең аноним булуы тәэмин ителә.

Аталган бәяләмә нигезендә һәр конкурс комиссиясе әгъзасы рефератны яки башка төрле язма эшне 100 баллы система буенча бәяли, түбәндәге критерияләр нигезендә:

рәсмиләштерүнең билгеләнгән таләпләренә туры килүе;

теманың ачылышы;

аналитик сәләтләре, мантыйкый фикерләве;

бирелгән тема буенча тапшырылган тәкъдимнәрнең нигезләнгән булуы һәм гамәлдә башкарып булучанлыгы.

Һәр критерия буенча максималь балл 25 балл тәшкил итә.

Бәяләмә нәтиҗәсе әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасына туры китерелгән формада рәсмиләштерелә.

4.13. Министрлыкта дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына керүгә) дәгъва белдергән кандидатларга тест уздыру Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты раслый торган Тест уздыру методикасына туры китереп гамәлгә ашырыла.

Тест уздыру юлы белән кандидатларның Россия Федерациясе дәүләт телен (рус телен) белү дәрәҗәсен, конституция законнары, дәүләт хезмәте турында һәм коррупциягә каршы көрәш турында законнар турындагы белемнәрен, Министрлыктагы тармак үзенчәлекләре турында белемнәрен, мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендәге белемнәрен, шулай ук идарәи компетенцияләрне үстерү дәрәҗәсен (тест уздырганда катнашучы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» категориясендәге вазыйфаны биләү өчен дәгъва белдерүчеләр өчен) бәяләү гамәлгә ашырыла.

Тест уздыруны оештыру Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан «Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

Тест уздыру Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнар өчен тест уздыруны оештыру мәсьәләләре» 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан расланган Тест уздыру методикасына туры китереп гамәлгә ашырыла.

Сорауларның һәм тест уздыруга әзерлек өчен юлламаларның үрнәк исемлеге Татарстан Республикасы рәсми порталында «Граждан һәм муниципаль дәүләт хезмәте» бүлегендә урнаштырыла.

Тест уздыру буенча максималь балл 100 балл тәшкил итә.

Тест уздыру нәтиҗәләре конкурс комиссиясе сәркатибе тарафыннан кыска белешмә рәвешендә рәсмиләштерелә.

4.14. Кандидатлар белән шәхси әңгәмә конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан уздырылырга тиеш. Шәхси әңгәмә уздыру барышында кандидатларның профессиональ дәрәҗәсен билгеләү максатында сораулар бирелә.

Беренчел шәхси әңгәмә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча конкурс уздырыла торган Министрлыкның структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан яисә кадрлар резервына кертү буенча конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча профессиональ хезмәт эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган дәүләт органының структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан уздырыла.

Конкурс комиссиясе утырышына кадәр беренчел шәхси әңгәмә уздыру нәтиҗәләре турында конкурс комиссиясенә конкурс комиссиясе утырышы барышында телдән доклад формасында аны уздырган зат тарафыннан мәгълүмат җиткерелә.

Шәхси әңгәмә барышында конкурс комиссиясе кандидатлар белән аларның тест узу, башка конкурс биремнәрен үтәү нәтиҗәләре хакында сүз алып бара, аларның профессиональ дәрәҗәсен һәм шәхси сыйфатларын билгеләү максатында сораулар бирелә.

Шәхси әңгәмә кандидатлар белән ирекле сөйләшү формасында уздырыла, аның барышында конкурс комиссиясе әгъзалары кандидатларга аларның компетенцияләрен ачыклау һәм кандидатларның белемнәренең һәм күнекмәләренең граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (аның буенча кадрлар резервы формалаштырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеменә) биләү өчен таләп ителгән, вазыйфаи регламентларда расланган белемнәргә һәм күнекмәләргә туры килүен билгеләүгә юнәлдерелгән сораулар бирелә.

Конкурс комиссиясе кандидатларны сорауларга бирелгән җавапларның тулылыгы һәм дөреслеге, кулланылган аргументларның дөрес сайлап алынуы, әйтү культурасы, рус телен белүе һәм аны белү дәрәҗәсе, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (аның буенча кадрлар резервы формалаштырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме) биләү өчен кирәкле булган кандидатларның белемнәрен, күнекмәләрен һәм белгәннәрен бәяләү буенча башка критерияләр буенча бәяли.

Шәхси әңгәмә уздыру йомгаклары буенча конкурс комиссиясе кандидатларны 100 баллы шкала буенча бәяли, түбәндәге критерияләр буенча:

100 балл – граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (аның буенча кадрлар резервы формалаштырыла торган вазыйфалар төркеме) өчен югары компетентлы;

90 балл – граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (аның буенча кадрлар резервы формалаштырыла торган вазыйфалар төркеме) өчен компетентлы;

80 балл – граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (аның буенча кадрлар резервы формалаштырыла торган вазыйфалар төркеме) өчен, тулаем алганда, компетентлы;

70-60 балл – граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (аның буенча кадрлар резервы формалаштырыла торган вазыйфалар төркеме) өчен компетенты чикле (бары тик тар даирә сораулар булганда яки квалификация үстерү шартында);

50 балл һәм азрак – граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (аның буенча кадрлар резервы формалаштырыла торган вазыйфалар төркеме) өчен компетентлы түгел (бары тик тар даирә сораулар булганда яки квалификация үстерү шартында).

Кандидатлар белән шәхси әңгәмә тәмамланганнан соң конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы 3 нче кушымтага туры китерелгән формада төзелә торган № 2 конкурс бюллетененә, кирәк булганда конкурс комиссиясе әгъзасы тарафыннан кабул ителгән карарны нигезләүче кыскача дәлилләмә белән, кандидатны бәяләү нәтиҗәсен терки

4.15. Кандидатның актыккы баллы конкурс процедуралары нәтиҗәсендә конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кандидатка куелган балларның уртача арифметик суммасы буларак билгеләнә.

Кандидатларның йомгак балларын чагыштыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе сәркатибе кандидатлардан рейтинг билгели.

Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс йомгаклары буенча конкурс комиссиясе карары һәм кадрлар резервына кертүгә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Аталган карар (беркетмә) туплаган балларын һәм конкурс комиссиясе тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча алар тарафыннан яуланган урыннарны күрсәтеп, кандидатлар рейтингын үз эченә ала.

4.16. Конкурсларны уздыру нәтиҗәсендә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасы) буенча барлык кирәкле таләпләргә җавап бирә торган кандидатлар ачыкланмаган очракта, конкурс комиссиясе өстәмә конкурс сынауларын үткәрү турында карар кабул итәргә яки яңа конкурс уздыру турында тәкъдим кертергә хокуклы.

4.17. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен конкурс нәтиҗәләре нигезендә министрның конкурста җиңүчене граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү турында боерыгы чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә.

4.18. Конкурс комиссиясе шулай ук тәкъдим холкына ия булган, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен конкурста җиңмәгән, ләкин профессиональ һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган һәм тупланган балларының гомуми исәбе максималь баллның кимендә 50 процентын тәшкил иткән кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында карар кабул итәргә хокуклы.

Кандидатның аны граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча кадрлар резервына кертүгә ризалыгы язмача формада яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында рәсмиләштерелә.

Граждан хезмәткәрен (гражданинны) – конкурста җиңүчене кадрлар резервына кертү министр боерыгы белән рәсмиләштерелә.

4.19. Конкурс нәтиҗәләре хакында хәбәрләр ул тәмамланганнан соң 7 көнлек чорда кандидатларга язмача рәвештә җиткерелә, шул ук вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга, Федераль мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә. Шушы ук чорда конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең күрсәтелгән мәгълүмат системасында да урнаштырыла.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) буенча конкурс уздыру турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрына

___________________________________________

(министрның инициаллары, фамилиясе)

кемнән

___________________________________________

(гариза тапшыручының инициаллары, фамилиясе)

Яшәгән адресы ________________________

___________________________________________

___________________________________________

Кесә тел. ________________________________

Электрон почтасы______________________

___________________________________________

**ГАРИЗА**

Мине Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен конкурста катнашырга кертүне сорыйм, түбәндәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен:

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

(вазыйфаның һәм бүлекчәнең аталышы)

_______________________________________________________________________________

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы указы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә белән, шул исәптән

вакантлы вазыйфага карата билгеләнә торган квалификация таләпләре белән, таныштым. Шәхси мәгълүматларымның «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп эшкәртелүенә риза.

Конкурс уздыру (тест уздыру) датасы һәм урыны турында e-mail яки күрсәтелгән кесә телефоны номерына СМС-хәбәр җибәрү ярдәмендә хәбәр алуга риза.

Гаризага түбәндәгеләрне теркәим:

______________________________________________________________________________

(теркәлә торган документларны санап чыгарга)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

___________ ________________________ ______________________

(дата) (имза) (тулы имза)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) буенча конкурс уздыру турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

№ 1 конкурс бюллетене

«__»___________________________ 20__ ел.
(конкурс уздыру датасы)

_______________________________________________________________________________
(аны биләү өчен конкурс уздырыла торган вазыйфаның тулысынча аталышы, яки
_______________________________________________________________________________
Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында аның буенча кадрлар резервына кертү өчен конкурс уздырыла торган вазыйфалар төркеменең аталышы)

Рефератларны яки башка төрле язма эшләрне бәяләү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзасы тарафыннан кандидатка бирелгән балл
(Белешмә өчен: максималь балл 100 балл тәшкил итә)

| Кандидатның номеры | Рәсмиләштерүнең билгеләнгән таләпләренә туры килә | Теманың ачылышы | Аналитик сәләтләре, мантыйкый фикерләве | Бирелгән тема буенча тапшырылган тәкъдимнәрнең нигезләнгән булуы һәм гамәлдә башкарып булучанлыгы | Актыккы балл |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

_____________________________________________ _____________________
(конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме) (имзасы)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) буенча конкурс уздыру турында нигезләмәгә 3 нче кушымта

№ 2 конкурс бюллетене

«__» ________ 20__ ел.
(конкурс уздыру датасы)

_______________________________________________________________________________
(аны биләү өчен конкурс уздырыла торган вазыйфаның тулысынча аталышы, яки
_______________________________________________________________________________
Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында аның буенча кадрлар резервына кертү өчен конкурс уздырыла торган вазыйфалар төркеменең аталышы)

Шәхси әңгәмә уздыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзасы тарафыннан кандидатка бирелгән балл

(Белешмә өчен: максималь балл 100 балл тәшкил итә)

| Кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Балл | Куелган баллга кыскача дәлилләмә (зарурлык булганда) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

_______________________________________________ __________________
(конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме) (имзасы)